Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Исләй авыл җирлеге Советы

КАРАР

2025 елның 27 марты № 54/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Исләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 27 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, аның график сурәте белән бергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://chistopol.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Исләй авыл җирлеге торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча җиткерергә:

Исләй авылы, 8 нче март ур., 19б йорт (административ бина);

Исләй ав., 8 нче март ур., 19а йорт (кибет)


3. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Исләй авыл җирлеге
башлыгы В.П. Чернышев

Чистай муниципаль районы
Исләй авыл җирлегенең
2025 елның 27 мартындагы
54/1 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Исләй авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № т/б | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче Мирный | Исләй авылы<br>Мирная урамы 1 нче йорттан алып 7 нче йортка кадәр<br>8 март ур. 1 нче йорттан 6 нчы йортка кадәр | 17 |
| 2 | 2 нче Түбән | Исләй авылы<br>8 нче март ур. 7 нче йорттан 35 нче йортка кадәр | 18 |
| 3 | 3 нче 8 нче март | Исләй авылы<br>8 нче март ур. 36 нчы йорттан алып 49 нчы йортка кадәр<br>Центральная ур. № 39, № 41 йортлар | 18 |
| 4 | 4 нче Центральный | Исләй авылы<br>Центральная ур. 22 нче йорттан алып 37 нче йортка кадәр | 20 |
| 5 | 5 нче Югары | Исләй авылы<br>Центральная ур. 11 нче йорттан 21 нче йортка кадәр<br>Заречная ур. 2 нче йорттан алып 6 нчы йортка кадәр | 20 |
| 6 | 6 нчы Ерак | Исләй авылы<br>Центральная ур. 1 нче йорттан алып 10а йортка кадәр | 19 |
| 7 | 7 нче Заречный | Исләй авылы<br>Зеленая урамы 1 нче йорттан 12 нче йортка кадәр<br>Заречная урамы №7, №8 йортлар | 18 |


Округ 3
8 Мартовский
Округ 2
Нижний
Округ 4
Центральный
Округ 7
Заречный
Округ 5
Верхний
Округ 1
Мирный
Округ 6
Дальний
клуб
СП
мечеть
школа
Округ 1 Мирный
Округ 2 Нижний
Округ 3 8-Мартовский
Округ 4 Центральный
Округ 5 Верхний
Округ 6 Дальний
Округ 7Заречный